**ЗАКОН**
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

# О внесении изменений в Закон Республики Татарстан «О реализации Федерального закона «Об организации регулярных перевозок пассажиров и багажа автомобильным транспортом и городским наземным электрическим транспортом в Российской Федерации и о внесении изменений в отдельные законодательные акты Российской Федерации»

Принят
Государственным Советом
Республики Татарстан
22 марта 2018 года

## Статья 1

Внести в Закон Республики Татарстан от 26 декабря 2015 года № 107-ЗРТ «О реализации Федерального закона «Об организации регулярных перевозок пассажиров и багажа автомобильным транспортом и городским наземным электрическим транспортом в Российской Федерации и о внесении изменений в отдельные законодательные акты Российской Федерации» (Ведомости Государственного Совета Татарстана, 2015, № 12 (I часть); 2016, № 7 – 8; Собрание законодательства Республики Татарстан, 2017, № 55 (часть I) следующие изменения:

1) в статье 3:
а) пункт $3^{1}$ части 1 признать утратившим силу;
б) пункт 8 части 2 признать утратившим силу;

2) в статье 5:
а) часть 2 изложить в следующей редакции:
«2. Муниципальные маршруты регулярных перевозок в границах одного городского поселения или одного городского округа устанавливаются, изменяются, отменяются уполномоченным органом местного самоуправления соответствующего городского поселения или соответствующего городского округа.»;
б) часть 3 изложить в следующей редакции:

«3. Муниципальные маршруты регулярных перевозок в границах одного сельского поселения, в границах двух и более поселений, находящихся в границах одного муниципального района, устанавливаются, изменяются, отменяются уполномоченным органом местного самоуправления муниципального района, в границах которого находятся указанные поселения.»;

в) часть 4 изложить в следующей редакции:

«4. Порядок установления, изменения, отмены муниципальных маршрутов регулярных перевозок, межмуниципальных маршрутов регулярных перевозок (в том числе порядок рассмотрения заявлений юридических лиц, индивидуальных предпринимателей, участников договора простого товарищества об установлении, изменении либо отмене данных маршрутов, а также основания для отказа в установлении либо изменении данных маршрутов, основания для отмены данных маршрутов) устанавливается:

1) в отношении муниципальных маршрутов регулярных перевозок – нормативными правовыми актами органов местного самоуправления;

2) в отношении межмуниципальных маршрутов регулярных перевозок – нормативным правовым актом уполномоченного органа исполнительной власти Республики Татарстан.»;

г) дополнить частью $4^1$ следующего содержания:

«$4^1$. Установление или изменение муниципального маршрута регулярных перевозок либо межмуниципального маршрута регулярных перевозок, имеющих два и более общих остановочных пункта с ранее установленным соответственно муниципальным маршрутом регулярных перевозок, межмуниципальным маршрутом регулярных перевозок, осуществляется по согласованию между уполномоченным органом исполнительной власти Республики Татарстан и уполномоченным органом местного самоуправления, к компетенции которых отнесено установление данных маршрутов. Порядок указанного согласования устанавливается Кабинетом Министров Республики Татарстан.»;

д) часть 6 изложить в следующей редакции:

«6. Если меньшие сроки не согласованы с юридическим лицом, индивидуальным предпринимателем или уполномоченным участником договора простого товарищества, которым выдано свидетельство об осуществлении перевозок по муниципальному маршруту регулярных перевозок, межмуниципальному маршруту регулярных перевозок, в течение срока действия такого свидетельства решение об изменении либо отмене соответствующего маршрута по инициативе установивших его уполномоченного органа исполнительной власти Республики Татарстан или уполномоченного органа местного самоуправления принимается не позднее чем за 180 дней до дня окончания срока действия такого свидетельства и вступает в силу по окончании срока действия такого свидетельства.»;

е) дополнить частью $6^1$ следующего содержания:

«$6^1$. В течение 60 дней со дня принятия уполномоченным органом исполнительной власти Республики Татарстан или уполномоченным органом местного самоуправления предусмотренного частью 6 настоящей статьи решения

об изменении муниципального маршрута регулярных перевозок, межмуниципального маршрута регулярных перевозок юридическое лицо, индивидуальный предприниматель, уполномоченный участник договора простого товарищества, которым выданы свидетельства об осуществлении перевозок по данным маршрутам, обязаны обратиться в уполномоченный орган исполнительной власти Республики Татарстан или уполномоченный орган местного самоуправления с заявлениями о продлении действия таких свидетельств и карт данных маршрутов на следующий срок в соответствии с принятым решением.»;

ж) часть 10 после слов «регулярных перевозок» дополнить словами «(за исключением сведений о месте жительства индивидуального предпринимателя)»;

3) в статье 6:

а) в части 1 слова «и нерегулируемым тарифам» исключить;

б) дополнить частью $1^1$ следующего содержания:

«$1^1$. Наряду с указанными в части 1 настоящей статьи маршрутами регулярных перевозок уполномоченный орган исполнительной власти Республики Татарстан, уполномоченные органы местного самоуправления вправе устанавливать межмуниципальные маршруты регулярных перевозок, муниципальные маршруты регулярных перевозок для осуществления регулярных перевозок по нерегулируемым тарифам.»;

4) в статье 7:

а) пункт 1 части 3 изложить в следующей редакции:

«1) после наступления обстоятельств, предусмотренных частью 10 статьи 24 либо пунктом 1, 2 или 7 части 1 статьи 29 Федерального закона, и до начала осуществления регулярных перевозок в соответствии с новым свидетельством об осуществлении перевозок по маршруту регулярных перевозок, выданным по результатам проведения открытого конкурса. По обстоятельствам, предусмотренным частью 10 статьи 24 Федерального закона, выдача свидетельства об осуществлении перевозок по маршруту регулярных перевозок и карт данного маршрута победителю открытого конкурса, признанного несостоявшимся, не допускается;»;

б) дополнить частью $3^1$ следующего содержания:

«$3^1$. Юридическое лицо, индивидуальный предприниматель, участники договора простого товарищества, которым свидетельства об осуществлении перевозок по муниципальному маршруту регулярных перевозок, межмуниципальному маршруту регулярных перевозок и карты соответствующих маршрутов выдаются без проведения открытого конкурса в случаях, предусмотренных частью 3 настоящей статьи, определяются в порядке, установленном нормативным правовым актом уполномоченного органа исполнительной власти Республики Татарстан, нормативным правовым актом органа местного самоуправления.»;

в) часть 4 изложить в следующей редакции:

«4. Без проведения открытого конкурса свидетельство об осуществлении перевозок по маршруту регулярных перевозок и карты маршрута регулярных перевозок выдаются в день наступления обстоятельств, которые явились основанием для их выдачи, один раз на срок, который не может превышать 180 дней, а в случае, если таким обстоятельством явилось приостановление действия ранее выданного свидетельства об осуществлении перевозок по данному маршруту, на срок приостановления действия указанного свидетельства.»;

г) в части 6:

пункт 1 изложить в следующей редакции:

«1) неоднократное в течение одного года непредставление в сроки, которые предусмотрены частью 2 статьи 37 Федерального закона, юридическим лицом, индивидуальным предпринимателем, уполномоченным участником договора простого товарищества ежеквартальных отчетов об осуществлении регулярных перевозок по маршруту регулярных перевозок;»;

в пункте 2 слова «частях 3 – 5» заменить словами «частях 4 и 5»;

пункт 6 изложить в следующей редакции:

«6) повторное в течение одного года нарушение требований к осуществлению перевозок по межмуниципальным маршрутам регулярных перевозок по нерегулируемым тарифам, установленных статьей $7^1$ настоящего Закона.»;

5) дополнить статьей $7^1$ следующего содержания:

«Статья $7^1$. **Требования к осуществлению перевозок по межмуниципальным маршрутам регулярных перевозок по нерегулируемым тарифам**

Юридические лица, индивидуальные предприниматели, участники договора простого товарищества при осуществлении перевозок по межмуниципальным маршрутам регулярных перевозок по нерегулируемым тарифам обязаны соблюдать требования, установленные законодательством Российской Федерации, настоящим Законом, в том числе обеспечить:

1) использование транспортных средств, оснащенных в установленном порядке аппаратурой спутниковой навигации ГЛОНАСС или ГЛОНАСС/GPS, и бесперебойную (в пределах установленного расписания маршрута регулярных перевозок) передачу информации с таких транспортных средств в Единую государственную информационную систему «ГЛОНАСС+112»;

2) исправную работу установленных в транспортном средстве оборудования для перевозок пассажиров из числа инвалидов, системы контроля температуры воздуха, электронного информационного табло, оборудования для безналичной оплаты проезда;

3) информирование в письменной форме уполномоченного органа исполнительной власти Республики Татарстан, владельцев автовокзалов и автостанций об изменении тарифа на перевозки по межмуниципальному маршруту регулярных перевозок за 30 календарных дней до изменения такого тарифа;

4) выполнение рейсов по межмуниципальным маршрутам регулярных перевозок исходя из максимально допустимого соотношения между количеством рейсов, не выполненных в течение одного квартала, и количеством рейсов, предусмотренным для выполнения в течение данного квартала установленным расписанием, составляющего не более трех процентов. К невыполненным не относятся рейсы, не выполненные вследствие дорожно-транспортных происшествий, произошедших по вине иных участников дорожного движения, снижения скорости движения транспортных средств, вызванного неблагоприятными погодными условиями или образовавшимися заторами на автомобильных дорогах, рейсы, не учтенные вследствие технических сбоев в информационной системе навигации, а также рейсы, не выполненные вследствие введения частичного ограничения или полного запрета движения транспортных средств по автомобильным дорогам при возникновении неблагоприятных метеорологических условий или чрезвычайной ситуации, отсутствия по маршруту регулярных перевозок объездного пути участка дороги при проведении ремонтно-строительных работ.»;

6) статью 8 признать утратившей силу.

**Статья 2**

1. Настоящий Закон вступает в силу со дня его официального опубликования, за исключением подпункта «ж» пункта 2 статьи 1 настоящего Закона.

2. Подпункт «ж» пункта 2 статьи 1 настоящего Закона вступает в силу с 28 июня 2018 года.

Президент
Республики Татарстан — Р.Н. Минниханов

АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН * ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ
ОБЩИЙ ОТДЕЛ
ГОМУМИ БҮЛЕК

Казань, Кремль
11 апреля 2018 года
№ 22-ЗРТ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

**“Россия Федерациясендә автомобиль транспортында һәм шәһәр җир өсте электр транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыру турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында” Федераль законны гамәлгә ашыру турында” Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2018 елның 22 мартында
кабул ителде

**1 статья**

“Россия Федерациясендә автомобиль транспортында һәм шәһәр җир өсте электр транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыру турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында” Федераль законны гамәлгә ашыру турында” 2015 елның 26 декабрендәге 107-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2015, № 12 (I өлеш); 2016, № 7 – 8; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 55 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 3 статьяда:
а) 1 өлешнең $3^{1}$ пунктын үз көчен югалткан дип танырга;
б) 2 өлешнең 8 пунктын үз көчен югалткан дип танырга;

2) 5 статьяда:
а) 2 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
“2. Бер шәһәр җирлеге яисә бер шәһәр округы чикләрендә даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципаль маршрутлары тиешле шәһәр җирлегенең яисә тиешле шәһәр округының вәкаләтле җирле үзидарә органы тарафыннан билгеләнә, үзгәртелә, туктатыла.”;
б) 3 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
“3. Бер авыл җирлеге чикләрендәге, бер муниципаль район чикләрендә урнашкан ике һәм аннан күбрәк җирлекләр чикләрендәге даими рәвештә

пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципаль маршрутлары күрсәтелгән җирлекләр үз чикләрендә урнашкан муниципаль районның вәкаләтле җирле үзидарә органы тарафыннан билгеләнә, үзгәртелә, туктатыла.";

в) 4 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"4. Даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципаль маршрутларын, даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципальара маршрутларын билгеләү, үзгәртү, туктату тәртибе (шул исәптән юридик затларның, индивидуаль эшкуарларның, гади ширкәт шартнамәсендә катнашучыларның шушы маршрутларны билгеләү, үзгәртү йә туктату турындагы гаризаларын карау тәртибе, шулай ук әлеге маршрутларны билгеләүдән йә үзгәртүдән баш тарту өчен нигезләр, шушы маршрутларны туктату өчен нигезләр) түбәндәгечә билгеләнә:

1) даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципаль маршрутларына карата – җирле үзидарә органнарының норматив хокукый актлары белән;

2) даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципальара маршрутларына карата – вәкаләтле Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органының норматив хокукый акты белән.";

г) түбәндәге эчтәлекле $4^1$ өлеш өстәргә:

"$4^1$. Даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның элек билгеләнгән тиешле муниципаль маршруты, даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның элек билгеләнгән тиешле муниципальара маршруты белән ике һәм аннан күбрәк уртак тукталыш пункты булган даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципаль маршрутын йә даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципальара маршрутын билгеләү яисә үзгәртү үз компетенцияләренә шушы маршрутларны билгеләү кергән вәкаләтле Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органы һәм вәкаләтле җирле үзидарә органы тарафыннан үзара килештереп гамәлгә ашырыла. Күрсәтелгән килештерү тәртибе Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнә.";

д) 6 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"6. Даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципаль маршруты, даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципальара маршруты буенча пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашыру турында таныклык бирелгән юридик зат, индивидуаль эшкуар яисә гади ширкәт шартнамәсенең вәкаләтле катнашучысы белән кыскарак сроклар килештерелмәгән булса, бу маршрутны билгеләгән вәкаләтле Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органы яисә вәкаләтле җирле үзидарә органы инициативасы белән мондый таныклык гамәлдә булган чор дәвамында тиешле маршрутны үзгәртү йә туктату турында карар мондый таныклыкның гамәлдә булу чоры тәмамлану көненә кадәр 180 көннән дә соңга калмыйча кабул ителә һәм әлеге таныклыкның гамәлдә булу чоры тәмамланганнан соң үз көченә керә.";

е) түбәндәге эчтәлекле $6^1$ өлеш өстәргә:

"$6^1$. Вәкаләтле Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органы яисә вәкаләтле җирле үзидарә органы тарафыннан даими рәвештә пассажирлар йөртүнең

һәм багаж ташуның муниципаль маршрутын, даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципальара маршрутын үзгәртү турында әлеге статьяның 6 өлешендә каралган карар кабул ителгән көннән алып 60 көн дәвамында шушы маршрутлар буенча пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашыру хакында таныклыклар бирелгән юридик зат, индивидуаль эшкуар, гади ширкәт шартнамәсенең вәкаләтле катнашучысы вәкаләтле Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органына яисә вәкаләтле җирле үзидарә органына кабул ителгән карар нигезендә мондый таныклыкларның һәм шушы маршрутлар карталарының гамәлдә булуын киләсе срокка озайту турында гаризалар белән мөрәҗәгать итәргә тиеш.";

ж) 10 өлештә "Даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж ташу маршрутлары реестрларына кертелгән белешмәләр" сүзләреннән соң "(индивидуаль эшкуарның яшәү урыны турындагы белешмәләрдән тыш)" сүзләрен өстәргә;

3) 6 статьяда:

а) 1 өлештә "һәм җайга салынмый торган тарифлар буенча" сүзләрен төшереп калдырырга;

б) түбәндәге эчтәлекле $1^1$ өлеш өстәргә:

"$1^1$. Әлеге статьяның 1 өлешендә күрсәтелгән даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж ташу маршрутлары белән берәттән вәкаләтле Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органы, вәкаләтле җирле үзидарә органнары җайга салынмый торган тарифлар буенча даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж ташу өчен даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципальара маршрутларын, даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципаль маршрутларын билгеләргә хокуклы.";

4) 7 статьяда:

а) 3 өлешнең 1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"1) Федераль законның 24 статьясындагы 10 өлешендә йә 29 статьясындагы 1 өлешенең 1, 2 яисә 7 пунктларында каралган шартлар барлыкка килгәннән алып даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж ташу маршруты буенча пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашыру турында ачык конкурс үткәрү нәтиҗәләре буенча бирелгән яңа таныклык нигезендә даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашыра башлаганчы. Үткәрелмәгән дип танылган ачык конкурста җиңүчегә даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж ташу маршруты буенча пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашыру турында таныклыкны һәм шушы маршрут карталарын бирү Федераль законның 24 статьясындагы 10 өлешендә каралган шартлар буенча рөхсәт ителми;";

б) түбәндәге эчтәлекле $3^1$ өлеш өстәргә:

"$3^1$. Даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципаль маршруты, даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципальара маршруты буенча пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашыру турында таныклыклар һәм тиешле маршрутлар карталары ачык конкурс үткәрелмичә генә әлеге статьяның 3 өлешендә каралган очракларда бирелгән юридик зат, индивидуаль эшкуар, гади ширкәт шартнамәсендә катнашучылар

вәкаләтле Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органының норматив хокукый актында, җирле үзидарә органының норматив хокукый актында расланган тәртиптә билгеләнә.";

в) 4 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"4. Ачык конкурс үткәрмичә генә даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж ташу маршруты буенча пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашыру турында таныклык һәм даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның маршрут карталары аларны бирү өчен нигез булып торучы шартлар барлыкка килгән көндә бер тапкыр, 180 көннән дә артыграк була алмый торган срокка, әгәр мондый шарт шушы маршрут буенча пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашыру турында элек бирелгән таныклыкның гамәлдә булуын туктатып торудан гыйбарәт булса, күрсәтелгән таныклыкның гамәлдә булуын туктатып тору срогына бирелә.";

г) 6 өлештә:

1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"1) юридик зат, индивидуаль эшкуар яисә гади ширкәт шартнамәсенең вәкаләтле катнашучысы Федераль законның 37 статьясындагы 2 өлешендә каралган срокларда даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж ташу маршруты буенча даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашыру турында һәр квартал саен бирелә торган хисапларны бер ел дәвамында берничә мәртәбә тапшырмаса;";

2 пунктта "3 – 5 өлешләрендә" сүзләрен "4 һәм 5 өлешләрендә" сүзләренә алмаштырырга;

6 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"6) даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципальара маршрутларында җайга салынмый торган тарифлар буенча пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашыруга карата әлеге Законның $7^1$ статьясында билгеләнгән таләпләрне бер ел эчендә кабат бозган очракта.";

5) түбәндәге эчтәлекле $7^1$ статья өстәргә:

"$7^1$ статья. **Даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципальара маршрутларында җайга салынмый торган тарифлар буенча пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашыруга таләпләр**

Юридик затлар, индивидуаль эшкуарлар, гади ширкәт шартнамәсендә катнашучылар даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципальара маршрутларында җайга салынмый торган тарифлар буенча пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашырганда Россия Федерациясе законнарында, әлеге Законда билгеләнгән таләпләрне үтәргә, шул исәптән түбәндәгеләрне тәэмин итәргә тиеш:

1) билгеләнгән тәртиптә ГЛОНАСС яисә ГЛОНАСС/GPS спутник навигациясе аппаратурасы белән җиһазландырылган транспорт чараларыннан файдалануны һәм мондый транспорт чараларыннан "ГЛОНАСС+112" бердәм дәүләт мәгълүмат системасына өзлексез рәвештә (даими рәвештә пассажирлар

йөртү һәм багаж ташу маршрутының билгеләнгән расписаниесе чикләрендә) мәгълүмат тапшыруны;

2) инвалид булган пассажирларны йөртү өчен транспорт чарасында куелган җиһазның, һава температурасын тикшереп тору системасының, электрон мәгълүмат таблосының, транспортта йөргән өчен акчаны күчереп түләү җайланмасының төзек эшләвен;

3) вәкаләтле Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органына, автовокзаллар һәм автостанцияләр хуҗаларына даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципальара маршруты буенча пассажирлар йөртү һәм багаж ташу тарифын үзгәртү турында мондый тарифны үзгәртүгә 30 календарь көн кала язмача хәбәр итүне;

4) бер квартал дәвамында үтәлмәгән рейслар саны һәм билгеләнгән расписаниедә шушы квартал дәвамында үтәлү өчен каралган рейслар саны арасында өч проценттан артык булмаган максималь рөхсәт ителгән аермадан чыгып, даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципальара маршрутлары буенча рейслар үтәүне. Үтәлмәгән рейсларга юл хәрәкәтендә башка катнашучыларның гаебе белән килеп чыккан юл-транспорт һәлакәтләре, уңайсыз һава шартлары яисә автомобиль юлларында барлыкка килгән тоткарлыклар аркасында килеп чыккан транспорт чаралары хәрәкәте тизлегенең кимүе сәбәпле үтәлмәгән рейслар, навигациянең мәгълүмат системасында техник өзеклекләр аркасында исәпкә алынмаган рейслар, шулай ук уңайсыз метеорологик шартлар яисә гадәттән тыш хәл килеп чыкканда транспорт чараларының автомобиль юллары буйлап хәрәкәтен өлешчә чикләүне яисә тулысынча тыюны кертүгә, ремонт-төзелеш эшләре үткәрелгәндә даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж ташу маршруты буенча юл участогын әйләнеп узу юлы булмауга бәйле үтәлмәгән рейслар керми.”;

6) 8 статьяны үз көчен югалткан дип танырга.

**2 статья**

1. Әлеге Закон, әлеге Законның 1 статьясындагы 2 пунктының “ж” пунктчасыннан тыш, рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

2. Әлеге Законның 1 статьясындагы 2 пунктының “ж” пунктчасы 2018 елның 28 июненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты — Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2018 ел, 11 апрель
№ 22-ТРЗ